ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2018 Казан ш. № 10-4/кс

Эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифларны әлеге карарга кушымтада каралган календарь бүленеш буенча билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны ачарга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 16 мартындагы 10-4/кс
номерлы карарына кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга календарь бүленеш белән тарифлар

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | - Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | - Ташландык суны чыгаруга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | Чүпрәле муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Перспектива» муниципаль унитар предприятиесе* | 33,02 | 34,35 | 32,60 | 34,21 |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | |
| 2 | «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | |
| 2.1 | «Салават күпере» торак районы кулланучылары | | | | |
| 2.1.1 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)** | | | 18,69 | 18,69 |
| 2.1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән) | | | 15,84 | 15,84 |
| | Яңа Чишмә муниципаль районы | | | | |
| 3 | «Яңа Чишмә ТКХ» муниципаль унитар предприятиесе* | 23,21 | 24,18 | | |

---

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге